ГЛАВА ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.04.2026 Алабуга шәһәре № 15

«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиген Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге белән чиктәш җирдә үзгәртү турында Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге тәкъдимнәрен исәпкә алып, Алабуга муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү турындагы мәсьәлә буенча фикер алышуда катнашучыларның хокукларын үтәү максатларында, гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән,

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрүне 2026 елның 8 маена 14.00 сәгатькә билгеләргә:


1.1. Алабуга муниципаль районының «Костенеево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче җир кишәрлекләрен Түбән Кама муниципаль районының «Красный Ключ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләренә кертү;

1.2. Түбән Кама муниципаль районының «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җир кишәрлекләрен Алабуга муниципаль районының «Танай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертү, 1 нче кушымта нигезендә.

2. Гавами тыңлаулар үткәрү урыны итеп: Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт адресында урнашкан Алабуга шәһәр Советының зур утырышлар залын билгеләргә.

Алабуга муниципаль районы Башлыгының
2026 елның 23.04.2026 15 номерлы карарына 1 нче кушымта

## Үзгәрешләрне исәпкә алып, Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләренең карта-схемасы




границы Елабужского муниципального района

границы поселений

административный центр поселения

населенный пункт

территория МО «Костенеевское сельское поселение» Елабужского муниципального района, планируемая квключению в границы МО «Красноключинское сельское поселение» Нижнекамского муниципального района

Территория МО «Простинское сельское поселение» Нижнекамского муниципального района, планируемая к включению в границы МО «Танайское сельское поселение» Елабужского муниципального района

Алабуга муниципаль районы Башлыгының
2026 елның 23.04.2026 15 номерлы карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр:

1.1. Алабуга муниципаль районының «Костенеево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче җир кишәрлекләрен Түбән Кама муниципаль районының «Красный Ключ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләренә кертү;

1.2 Түбән Кама муниципаль районының «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җир кишәрлекләрен Алабуга муниципаль районының «Танай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертү, 1 нче кушымта нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә түбәндәге адрес буенча шәхсән яки почта аша (конвертта «Төзекләндерү кагыйдәләрен тикшерү» яки «Гавами тыңлаулар» тамгасы белән) бирелә: 423603, Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 12 нче йорт.

2. Тәкъдимнәр карар проекты рәсми басылып чыккан көннән 2026 елның 7 маена кадәр эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Алабуга шәһәре, Мира проспекты, 12 нче йорт, 214 нче номерлы кабинет яисә почта аша («Гавами тыңлаулар» конвертында тамга белән) яки 4-56-04 телефоны аша язмача рәвештә гавами тыңлаулар тамгасы белән кертелә

4. Гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге тарафыннан теркәлә.